**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2716**
**27.05.2022**

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 6 апрелендәге 1695 номерлы, 2020 елның 12 октябрендәге 5229 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 7278 номерлы, 2021 елның 31 мартындагы 2191 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге 4177 номерлы, 2021 елның 3 декабрендәге 7863 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 8099 номерлы, 2022 елның 21 гыйнварындагы 225 номерлы, 2022 елның 25 мартындагы 1620 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программа чараларын финанслауны «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетында «Гаиләне һәм балачакны саклау» 1004, «Халыкны социаль тәэмин итү» 1003, «Коммуналь хуҗалык» 0502, «Транспорт» 0408 бүлекләре буенча каралган акчалар

хисабына 375306,04 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2020 ел – 23606,75 мең сум; 2021 ел – 147847,90 мең сум; 2022 ел – 203851,39 мең сум.»;

2) 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасында:

- 1 бүлекне 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2020-2022 елларга программаны финанслау күләме 375306,04 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Чор өчен барлыгы 375306,04 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2020 ел – 23606,75 мең сум;

2021 ел – 147847,90 мең сум;

2022 ел – 203851,39 мең сум.»;

- 6 бүлекне 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 27 маендагы
2716 номерлы карарына
1 нче кушымта

1 бүлек. 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокук актының исеме, номеры һәм датасы) | «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы;<br>Татарстан Республикасы Президентының «Бер үк вакытта өч һәм аннан да күбрәк бала тууга бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 елның 20 августындагы ПУ-397 номерлы Указы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 елның 28 декабрендәге 708 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе |
| Программаның максаты | Халыкның аерым категорияләренә: пенсионерларга, инвалидларга, балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, гаиләнең социаль статусын күтәрү |

<table>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1. Халыкның аз керемле категорияләренә яки катлаулы тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү.<br>2. Хәрби бәрелешләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид балалар, өлкән буын кешеләре өчен бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү.<br>3. Инвалидларның бәйсез тормышы өчен шартлар булдыру, аларны җәмгыятькә интеграцияләү.<br>4. Халыкның социаль проблемаларны мөстәкыйль чишү мөмкинлекләренә ия булмаган социаль зәгыйфь категорияләрен мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк яклауны тәэмин итү. Өлкән яшьтәге гражданнарның җәмгыять тормышында актив катнашуына булышлык итү.<br>5. Аз керемле гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү.<br>6. 4 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары, инвалид балалары булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">Программа 2020 – 2022 елларда тормышка ашырыла.<br>Муниципаль программаның этаплары аерып күрсәтелми.</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2020 ел (мең сум)</td><td>2021 ел (мең сум)</td><td>2022 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>23606,75</td><td>147847,90</td><td>203851,39</td><td>375306,04</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Халыкның аз керемле һәм социаль зәгыйфь төркемнәрен нәтиҗәле адреслы социаль яклау, авыр тормыш хәлендә калган инвалидларга, халыкның аз керемле категорияләренә төрле юнәлештәге ярдәм күрсәтүнең дәрәҗәсен яхшырту</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы</td><td colspan="5">Программа үтәлешенә контрольне Башкарма комитетның мәгариф идарәсе гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 27 маендагы
2716 номерлы карарына
2 нче кушымта

6 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләүнең индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару срогы (ел саен) | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 (база) | 2020 кеше | 2021 кеше | 2022 кеше | 2020 (мең сум) | 2021 (мең сум) | 2022 (мең сум) |
| | | | | | | | | | муниципаль бюджет | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максатның исеме: халыкның аерым категорияләренә: пенсионерларга, инвалидларга, балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, гаиләнең социаль статусын күтәрү | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Халыкның аз керемле категорияләренә яки катлаулы тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Халыкның аз керемле категорияләренә яки:<br>1) катлаулы тормыш хәлендә калган;<br>2) туганлык мөнәсәбәтләрендә булган кешесенең янгын вакытында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә яки башка шундый сәбәп буенча үлеме нәтиҗәсендә авыр тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 4 гаилә | 4 гаилә | 4 гаилә | 4 гаилә | 50,0 | 80,0 | 80,0 |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 50,0 | 80,0 | 80,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч. Хәрби бәрелешләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид балалар, өлкән буын кешеләре өчен бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | |
| 2. | Әфганстандагы хәрби бәрелешләрдә катнашучы-инвалидларны, һәлак булганнарның гаилә әгъзаларын бүләкләү (15 февраль – Әфганстан Республикасыннан гаскәрләрне чыгару көне) | Башкарма комитетның район хакимиятләре | 15 февраль | кеше саны | 112 | 112 | 112 | 112 | 112,00 | 111,99 | 112,00 |
| 3. | 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан хатын-кызларны – сәләтле балалары булган күп балалы аналарны бүләкләү | Башкарма комитетның ГХАТ идарәсе | 8 март | кеше саны | 30 | 30 | 30 | 30 | 40,00 | 0,0 | 40,00 |
| 4. | 9 май – Җиңү көне уңаеннан Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм ветераннарга истәлекле бүләкләр | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 1 – 10 май | кеше саны | 60 | 60 | 60 | 60 | 123,35 | 149,93 | 150,00 |
| 5. | 26 сентябрь – Бөтендөнья саңгыраулар көнендә Саңгыраулар җәмгыяте активистларын бүләкләү | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 26 сентябрь | кеше саны | 20 | 20 | 20 | 20 | 16,60 | 15,08 | 20,0 |
| 6. | Өлкән буын көненә багышланган тантаналы чара үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 1 октябрь | кеше саны | 158 | 158 | 158 | 158 | 127,08 | 120,12 | 158,0 |
| 7. | 13 ноябрь – Бөтендөнья сукырлар көнендә Сукырлар җәмгыяте активистларын бүләкләү | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте | 13 ноябрь | кеше саны | 20 | 20 | 20 | 20 | 20,00 | 20,00 | 20,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Сәләтле балалары булган һәм производствода уңышлы эшләүче хатын-кызларны – күп балалы аналарны бүләкләү (27 ноябрь – Әниләр көне) | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 27 ноябрь | кеше саны | 75 | 75 | 75 | 75 | 145,25 | 147,49 | 150,00 |
| 9. | Халыкара инвалидлар көненә багышланган спорт һәм мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 1–10 декабрь | кеше саны | 1 200 | 1 200 | 1 200 | 1 200 | 178,93 | 204,80 | 210,00 |
| 10. | Ватан Геройлары көненә багышланган тантаналы чаралар үткәрү | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте | 9 декабрь | кеше саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 40,00 | 40,00 | 40,00 |
| 11. | Яр Чаллы шәһәре һәм Татарстан Республикасы үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны, Мактаулы гражданнарны җирләү чаралары | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 1 | 2 | 2 | *2* | 39,00 | 3,10 | 20,00 |
| 12. | «Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы» исеме бирелгән затларга айлык акчалата түләүләр түләү | Башкарма комитет | ел дәвамында | кеше саны | 111 | 111 | 111 | 111 | 1425,12 | 1353,82 | 1533,06 |
| 13. | Бөек Ватан сугышы ветераннарын, хәрби бәрелешләр ветераннарын, төзүче-ветераннарны календарь бәйрәмнәр (23 февраль, 8 Март, 9 Май) белән, шәһәр һәм республика үсешенә зур өлеш керткән юбилярларны (90, 95, 100 яшь һәм өлкәнрәк) котлау | Башкарма комитет | ел дәвамында | кеше саны | 0 | 300 | 300 | 300 | 585,92 | 564,31 | 565,97 |
| | Барлыгы: | | | | 1791 | 2092 | 2092 | 2092 | 2853,25 | 2730,64 | 3019,03 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 бурыч. Инвалидларның бәйсез тормышы өчен шартлар булдыру, аларны җәмгыятькә интеграцияләү | | | | | | | | | | | |
| 14. | «Инвалидлар өчен Сабан туе» шәһәр бәйрәме үткәрү | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте | июнь | кеше саны | 2 000 | 2 000 | 2 000 | 2 000 | 114,09 | 278,82 | 280,00 |
| 15. | Физик культуры һәм спорт аша инвалидларны, инвалид балаларны социаль-мәдәни тернәкләндерү чаралары | Физик культура һәм спорт идарәсе Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 120 | 360 | 360 | 360 | 292,34 | 297,71 | 410,00 |
| 16. | Сәнгать иҗаты аша инвалидларны, инвалид балаларны җәмгыятькә социаль җайлаштыру чаралары үткәрү:<br>1) инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең район турлары;<br>2) инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең Гала – концерты | Башкарма комитетның район хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 450 | 750 | 750 | 750 | 182,31 | 89,20 | 190,00 |
| 17. | Инвалидларның югары уку йортларында укулары өчен өлешчә түләү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 30 | 30 | 30 | 30 | 90,00 | 90,00 | 90,00 |
| 18. | Иҗтимагый оешмалар активистларына материаль стимуллаштыру чаралары бирү:<br>- Ветераннар Советы;<br>- Инвалидлар җәмгыяте;<br>- Сукырлар җәмгыяте;<br>-Саңгыраулар җәмгыяте; | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | оешмалар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 697,20 | 697,20 | 697,20 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - Репрессиягә дучар булучылар җәмгыяте | | | | | | | | | |
| 19. | Иҗтимагый оешмаларның элемтә хезмәтләреннән файдалану чыгымнарын компенсацияләү, коммуналь түләүләрен түләү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | оешмалар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 71,67 | 90,85 | 96,55 |
| | Барлыгы: | | | | 2609 | 3149 | 3149 | 3149 | 1447,61 | 1543,78 | 1763,75 |
| 4 бурыч. Халыкның социаль проблемаларны мөстәкыйль чишү мөмкинлекләренә ия булмаган социаль зәгыйфь категорияләрен мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк яклауны тәэмин итү. Өлкән яшьтәге гражданнарның җәмгыять тормышында актив катнашуына булышлык итү | | | | | | | | | | |
| 20. | Күп балалы, аз керемле, аеруча мохтаҗ гаиләләргә, балигъ булмаган балалары булган авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә мәктәпкә әзерләнгәндә материаль ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | июль, август, сентябрь | гаиләләр саны | 750 | 750 | 750 | 750 | 1 000,00 | 1 000,00 | 1 000,00 |
| 21. | Инвалид балаларга, аз керемле гаиләләрдәге балаларга Яңа ел чаралары үткәрү | Башкарма комитетның район хакимиятләре Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | декабрь | балалар саны | 1 500 | 1 500 | 1 500 | 1 500 | 206,60 | 210,96 | 400,00 |
| 22. | Бер үк вакытта өч бала тапкан аналарга материаль ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның район хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 50,00 | 0,0 | 50,00 |
| 23. | Ташламалы йөрү хокукыннан файдаланучы гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек яки дача коммерцияле булмаган берләшмәләренә пассажирлар йөртүне оештыру | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | пассажирлар йөртү саны | 11 311 | 11 311 | 11 311 | 11 311 | 14999,29 | 14999,48 | 15 000,0 |
| | Барлыгы: | | | | 13563 | 13563 | 13563 | 13563 | 16255,89 | 16210,44 | 16450,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 бурыч. Аз керемле гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| 24. | Мунча хезмәтләре күрсәтү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | күрсәтелгән хезмәтләр саны | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 3 000,00 | 3308,05 | 3 000,00 |
| | Барлыгы: | | | | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 3 000,00 | 3308,05 | 3 000,00 |
| 6 бурыч. 4 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары, инвалид балалары булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| 25. | Муниципаль белем бирү оешмаларында укучы инвалид балаларны, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны, 3 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны түләүсез кайнар аш белән тәэмин итү | Башкарма комитет | ел дәвамында | балалар саны | - | - | | 6404 | - | 123974,99 | 121418,81 |
| 26. | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны тукландыруны тәэмин итү | | | | | | | | | | 58119,80 |
| | Барлыгы: | | | | - | - | | | - | 123974,99 | 179538,61 |
| | Барысы: | | | | 72 670 | 73511 | 74783 | 74783 | 23606,75 | 147847,9 | 203851,39 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева